

«Призыв» газетасы мәгълvматлары буенча, хәзерге вакытта торле милләт вәкилләре, шул исәптән татарлар да яшәгән Лэмберә районы Болотниково авыл жирлегенен алты торак пунктында 652 кеше гомер итә.
Быел, барлыгы 30 кеше эшләгән «Болотниковское» жирле авыл хужалыгы предприятиесе, һәр гектар чәчvлекнен уртача унышы 33 центнер белән, vз басуларыннан 1 мен 485 тонна икмәк жыеп, бортекле һәм кузаклы культураларны урып-жыюны унышлы тәмамлаган.

Моннан тыш, болотниклылар районда беренче булып 200 гектарда артык козге культуралар чәчкәннәр. Ипи, бәрәнгебез (Мордовиядә быел анардан да мул уныш жыйдык) булганда – без тук, дип әйтә торган иде картларыбыз. Фотодагы (сулдан унга): тракторчы Әнвәр Арысланов, комбайнчы Николай Чудаев, хужалыкнын баш инженеры Шамил Баймашкин, «Болотниковское» идарәчесе Василий Потяйкин һәм комбайнчы Сергей Ямбулатов барлык авыл хужалыгы эшләрендә vзләренен тырышлыклары аркасында мактаулы хезмәткәрләр рәтендәләр.
Табигать капризларына карамастан (суык май һәм аннан сонгы озын янгырлар), Болотниково йорт яны учас-токларында суган һәм сарымсак аеруча кvп булды. Әмма бер проблема - бvгенге кондә артык бакча продукциясен сатарга урын юк. Бу бәрәнгегә дә кагыла. Авыл халкынын кайберләре бәрәнгене кая куярга белмиләр: элек йорт хайваннарын кvп тоткannар һәм бәрәнгенен кvп олеше терлек азыгына киткән. Ә бvген биредә ун сыер да калмаган, берничә кәжәләре белән!
Календарьда коз, ә һава торышы әлегә жәйгечә. Болотниковода олкән яшьтәге кешеләр һәм балалар жылы коннәргә аеруча шатланалар. Кvптән тvгел авыл vзәгендә (авыл жирлеге администрациясе бинасы һәм жирле клуб янында) урнашкан балалар уен мәйданчыгы яныннан пенсия яшендәге әбиләр, оныклары һәм оныкчыклары белән рәхәтләнеп ял итәләр. Әйтеп китәргә кирәк, бу мәйданчык авылда берничә ай элек халыкнын инициативасы һәм жирле vзидарә органы ярдәме белән тозелгән. Кыска вакыт эчендә халык 55 мен сум акча жыйган. Елена Александровна Чекалдаева житәкчелегендәге жирле хакимият, рефинанслау шартларында респуб-лика бюджетыннан остәмә рәвештә 220 мен сум алу очен, барлык кирәкле кәгазьләрне рәсмиләштергәннәр һәм бvген балалар очен ял урыны тозелгән.
Болотниковода балалар мәйданчыгы тозv буенча барлык мәшәкатьләрне жирле эшмәкәр И.В.Баранов vз остенә ала. Иван Васильевич объектны vз проекты буенча този, барысын да vз куллары белән эшли. Участокны планлаштырудан башлап, физик кvнегvләр һәм тренажерларны буяу очен уен элементлары һәм конструкцияләре урнаштыруга кадәр.
- Буш вакытыбызны шушы мәйданчыкта уздыру безгә бик ошый, - ди хезмәт ветераны Рива Абубәкәр кызы Аитова vзенен шатлыклы хисләрен белдереп. - Жылы, янгырсыз

һава торышында биредә егермегә кадәр кеше жыела. Балалар уйныйлар һәм кvнел ачалар, ә без, олкәннәр, бер-беребез белән аралашабыз һәм тирә-юньдәге матурлыкка сокланабыз. Әлбәттә, мәйданчыкнын ботен периметры буйлап куаклар – балан, сирень, ясмин, кара жимешле миләш утыртырга теләк бар иде; субботник оештырып утыртырбыз. Ә мәктәп яше Болотниково балаларын (12 укучы) кvрше Пензятка авылы мәктәбенә махсус автобуста йортәләр.
Тагы бер хәбәр - Авыл администр-ациясендә хәзерге вакытта Болотниково авыл жирлегенә керvче кечкенә торак пунктларны газлаштыру белән бәйле проект-смета документациясе эшләнә диләр. Мондый исемлеккә әлегә Советское, Акаевка һәм Мельцапино авыллары керә. Дәvләт аларнын да табигый зәнгәр ягулык белән яшәвен тели.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**